ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме җиденче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме җиденче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 238-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
2. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 237-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
3. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 206-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
4. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 231-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
5. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 239-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
6. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы

Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 245-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Татарстан Республикасында умартачылыкны үстерү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 236-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 246-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 248-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы проекты турында.

11. Профессиональ даими нигездә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын сайлау турында.

12. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составындагы үзгәрешләр турында.

13. 2020 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады.

14. Татарстан таможнясы эшчәнлеге турында мәгълүмат.

15. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына экскурсоводлар (гидлар), гидлар-тәрҗемәчеләр һәм озатып йөрүче инструкторлар эшчәнлеген хокукый җайга салу өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1212915-7 номерлы федераль закон проекты турында.

16. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1245543-7 номерлы федераль закон проекты турында (җитештерү һәм куллану калдыклары белән территорияләрне пычратуга бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылыкны арттыру хакында).

17. «Ветераннар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 3060-8 номерлы федераль закон проекты турында (Чечен Республикасында һәм кораллы конфликт зонасына кертелгән аңа чиктәш Россия Федерациясе территорияләрендә кораллы конфликт шартларында һәм Төньяк Кавказ регионы территориясендә контртеррористик операцияләр барышында хезмәт вазыйфаларын башкарган Россия Федерациясе прокуратура органнары прокурорларына һәм тикшерүчеләренә, Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләренә хәрби хәрәкәтләр ветераны статусын бирү һәм тиешле социаль ярдәм чараларын билгеләү хакында).

18. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 71 статьясына үзгәреш кертү хакында» 5463-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби хәрәкәтләр барышында һәлак булган яисә имгәнүләрдән үлгән хәрби хәрәкәтләр ветераннарының балаларына билгеләнгән квота чикләрендә югары уку йортларына укырга кабул ителү хокукы бирү өлешендә).

19. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 50 һәм 56 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 11602-8 номерлы федераль закон проекты хакында (тәмәке продукциясенә акцизлардан салым керемнәрен 50 процент норматив буенча Россия Федерациясе субъектлары бюджетына кертү өлешендә).

20. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 26 һәм 38 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасы закон чыгару инициативасы турында.

21. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында халык сәнгать һөнәрләрен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 18 ноябре
№ 1189-VI ДС